
# Әйләнә-тирәбездәге дөнья

- Кыргый хайваннар кышын.




# Нинди матур кышкы урман!



Ак ашъяулык
таптым,

Җир өстенә
яптым.



Урманнар артыннан
Һәм таулар артыннан,
Килә Кыш бабай
Ай, суык, ай-ай-ай.


Тәңкә карлар сипкән,
Җирне ап-ак иткән,
Чыршы, каен,имән
Кардан чикмән кигән.
Бу кайчак?



Ул өстенә җәй дә,кыш та
Энәле күлмәк кия.
Шулай да аны әнкәсе
Йомшагым, диеп сөя.




Бер куышы кипкән гөмбә
Чикләвек белән тулы.
Азык мул.Озын булса да
Кышның буранлы юлы.


Ак кар.
Кызыл төлке-
Яшел күзле,
Зәңгәр эзле.
.


Алты тәпие кыска,
Чабарга ул бик оста,
Соры тунын сала да,
Ак тунын кия кышта.

# Белемнәрне ныгыту.

1.Нинди җәнлекләр кышка тунын алыштыра?

2.Запас азыгы булмаса, тиен нәрсә ашый?

3.Куян ни өчен карда батмый?

4.Тиеннең йомшак койрыгы сикерергә комачауламыймы?



5.Төлке белән этнең кардагы эзләре ни белән аерыла?



# Җөмләне тәмамла.

Кышны нәрсә ничек үткәрә?


**Йоклый...**

**Запас белән яши...**

**Кышкы тунын кия...**

**Кеше торагы тирәсенә килә...**

**Дөрес җавапны тап:**
**(керпе,тиен,аю,төлке, песнәк,куян,чыпчык, ала карга)**



# Әдәбият

1. А.А.Плешаков «Әйләнә-тирәбездәге дөнья»
2. Б.Б.Запартович «Табигатькә сөю белән”.
3. А.А.Плешаков дәреслегенә ярдәмлек.